
**Буа шәһәре 5 нче гимназия**

**Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,**
**Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.**
**Театр — яктылыкка, нурга илтә,**
**Кире юлга җибәрми, уңга илтә.**
**Габдулла Тукай.**



# “Нур” театраль түгәрәге
# 2025-2026 нчы уку елы

**Җитәкче. Абзалова Э.Р.**

**“Нур” театраль түгәрәгенең отчеты**

**Җитәкче. Абзалова Э.Р.**

“Нур ” театраль түгәрәгенә 4 нче һәм 9 нчы сыйныф укучылары бик теләп йөрделәр. Театр - балалар өчен сәнгатьнең иң аңлаешлы бер төре. Театральләштерелгән уеннар балачак дөньясына юл ача. Театральләштерелгән уеннарны балалар бик яраталар, чынбарлык итеп кабул итәләр, һәрбер бала үз ролен уйнарга тели. Моңа ничек ирешергә? Театр балаларның иҗади һәм рухи потенциалларын ачарга, социаль тирәлеккә яраклашырга ярдәм итә. Алар үзләрен иркле, табигый тоталар, иркен хис итәләр, сәләтләре ачыла. Уеннар аша сабыйлар шәхес буларак җәмгыятьтә үз урыннарын табарга өйрәнәләр, әйләнә – тирә белән танышалар, әхлак нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәгәндә мөстәкыйльлек күрсәтәләр, дөрес фикерлиләр, иҗади сәләтләре ачыла. Театральләштерелгән уеннар күп кенә актуаль педагогик һәм психологик проблемаларны чишәргә ярдәм итәләр, бигрәк тә:

- шәхеснең коммуникатив яктан үсүен тәэмин итү;
- әхлак тәрбиясе бирү;
- эстетик зәвык формалаштыру;
- сөйләм телен үстерү һәм камилләштерү;
- конфликтлы очракларны чишәргә күнектерү, уңай эмоциональ халәт тудыру;
- хәтерне үстерү, ихтыяр көче тәрбияләү.

Түгәрәк эшчәнлеге уңышлы һәм нәтиҗәле узсын өчен:

-тиешле педагогик шартлар тудырылды,

- өйрәтү эшчәнлеге яңартылды,

-нәтиҗәле алымнардан файдаланылды,

Тәкъдим ителгән материал балаларны олы, катлаулы, гаять кызыклы театр дөньясына алып керүдә һәм театраль белем серләренә өйрәтүдә файдалы ярдәмлек булыр дип ышанам.

## Программаның максаты

Театральләштерү алымнарын кертү аша балаларда театр сәнгатенә кызыксыну һәм омтылыш, зур сәхнәдә чыгыш ясап үзеңне сынап карау теләге уяту; балалар әдәбиятының иң матур үрнәкләре, татар халык авыз иҗатының төрле формалары белән таныштыру аша әдәби телдә сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү, эстетик зәвыкларын, иҗади сәләтләрен, башкару осталыкларын үстерү; халкыбызның әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте, гореф-гадәтләре үрнәгендә әхлаклы, югары культуралы шәхесләр тәрбияләү.

## Программаның бурычлары

- Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, баланың сүз байлыгын арттыру, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләү;
- хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;
- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү ;
- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация тәэсирле чараларын кабатлау теләге тудырылды.

- музыка  һәм  хореография  сәнгате нигезләре белән таныштырылды;
- балаларда  эстетик,  әхлак  һәм  хезмәт  тәрбиясен  тормышка ашыру;
- балаларның сәламәтлеген  яхшырту;
- сәнгатькә  кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

## Шундый нәтиҗәгә ирешелде:

1. Балалар милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белделәр.
2. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үстерелде.
3. Сәхнәләштерү  уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыртылды, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары артты, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре тудырылды. Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенделәр.
4. Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында  мәгълүмат тупланды.
5. Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәбәт урнаштырылды.


## “Нур” түгәрәге коллективы төрле фестиваль-конкурсларда катнашып, призлы урыннар яуладылар.











## Фестиваль- конкурс детско-юношеских театральных коллективов «Искусство. Вдохновение. Талант.









## “Ният” Татар балалар фестивале











# Театральная постановка в конкурсе «Без бергә”






## “Сәяр” балалар фестивале




## Фестиваль «Победа в наших сердцах»




2025
Год защитника Отечества
80-летие Победы
в Великой Отечественной
войне
80
ПОБЕДА!







